# Шәһри Казан

ҖОМГА, 4 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 2 (5180)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

## КӨН АВАЗЫ

Мөхәммәд пәйгамбәр турындагы мажаралы китап дөнья күргән. Пәйгамбәрнең «Мөхәммәд тормышы» дигән сатирик биографиясен элек аның турындагы карикатуралар публикациясен бастырган Франциянең «Шарли эбдо» журналы редакциясе нәшер иткән. Журналның баш мөхәррире әйтүенчә, китаптагы публикация ислам диненә каршы килми, чөнки аны басмага тумышы белән Тунистан булган француз социологы әзерләгән. «Минемчә, мөселманнар әлеге китаптан килешмәгән әйберләр тапмаслар», – ди китапны бизәүче Стефан Шарбонье.

***

Кытайлыларны кунакка йөрергә мәҗбүр итәчәкләр. Кытай хөкүмәте балигъ булган балаларны әти-әниләре янына хәл белергә баруны мәҗбүр итүче закон кабул иткән. Әмма анда елына яки аена ничә тапкыр барырга кирәклеге турында әйтелмәгән. Яңа закон нигезендә үзләре янына килеп йөрмәгән балаларын кытай пенсионерлары судка бирә ала икән. Соңгы вакытта Кытайда караучысыз калган әти-әниләр күбәеп киткән. Бу исә илдәге «Бер гаилә – бер бала» сәясәте белән аңлатыла. Әйтүләренчә, әлеге сәясәт зур гаиләләрдәге традицияләрнең югалуына китергән.

***

Нью-Йорк хакимияте америкалыларга тискәре хатирәләрдән арынырга ярдәм итәргә булган. Моның өчен шәһәр үзәгендәге Таймс скверында кәгазьне ваклый торган махсус аппарат – предер урнаштырылган. Теләгән һәр кеше үзе белән булган күңелсез вакыйгалар язылган кәгазь кисәген шул аппаратка сала икән. Хәбәр итүләренчә, халык, чиратлап, штрафлар турындагы квитанцияләрен, элеккеге ирләре яки хатыннарының фотосурәтләрен, күңелсез хәбәрләр язылган журналларны, тискәре медицина анализлары кәгазьләрен аппаратка туратырга сала ди. Кәгазьдән кала башка әйберләрен алып килүчеләр исә аларны махсус чүкеч белән ватып ташлый икән.

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

# БОЗ ШӘҺӘРЧЕГЕНӘ БАРЫГЫЗ!

**Мәгълүм булганча, РФ Мәдәният министрлыгының карары нигезендә, быел Казан Россиянең Яңа ел башкаласы итеп сайланган иде. Шунлыктан, шәһәребездә 70 урында чыршы мәйданчыклары оештырылды. Казанның төп чыршысы Островский урамындагы Меңьеллык паркына урнаштырылган. Җыелма чыршының биеклеге 40 метрдан артык. Великий Устюг шәһәреннән Дед Мороз да килде. Ул, татар Кыш бабае һәм Кар кызы белән берлектә, төрле бәйрәм чараларында катнаша.**

КАНИКУЛ

**Дамир БӘДРИЕВ**

«Әкият» Татар дәүләт курчак театры каршындагы мәйданда әле узган елның 28 декабрендә үк сихри боз шәһәрчеге үзенең капкаларын ачты. Боз койма белән уратып алынса да, сабыйлар шәһәрчеккирмәнне шау-гөр килеп яулый гына. Ниләр генә юк биредә: боздан ясалган төрле сыннар, шугалаклар дисеңме!.. Өч урынга матур итеп чыршы бизәлгән. Тәвәккәлрәк сабыйлар лабиринтка кереп китә, әмма күпләре адаша. «Әкият» курчак театрының мәһабәт сарае боз шәһәрчегендә әкияттәгедәй манзара тудыра. Монда төрле чаралар Яңа ел яллары дәвамында үткәреләчәк. Боз шәһәрчегенең «Сукно бистәсе» метро станциясе янәшәсендә генә булуы Казанның төрле районнарыннан килеп ял итәргә, саф һавада уйнап күңел ачарга мөмкинлек тудыра. Меңьеллык паркындагы төп Чыршыга да ерак түгел.

Балаларын иярткән ата-аналар, яшьләр метро станциясеннән боз шәһәрчегенә агыла гына. Бәйрәм сәфәре аянычлы тәмамланмасын өчен, вакытлыча гына булса да, Санкт-Петербург урамы юлына «Җәяүле» билгесе куеп торасы иде.

Черек күлдәге чыршы мәйданчыгы да күңелгә хуш киләчәк. Дөрес, анысында боз шәһәрчеге юк югын, әмма тимераякларда рәхәтләнеп шуар өчен боз мәйданы бар. Химиклар мәдәният сарае янәшәсендәге бакчада да чыршы мәйданчыгы булдырылды. Анда шулай ук кечерәк боз шәһәрчеге төзелде, лунапарк аттракционнары эшли.

Казанда боз шәһәрчекләре төзү традициясе соңгы елларда онытыла төшкән иде, мәдәният идарәсе традицияләрне яңартырга ниятли. Әйдәгез әле, өйдә утырмыйк, саф һавага чыгып, көчдәрт туплыйк!

## БАШКАЛАДА

### Кыш бабай рәсем дә ясый белә

«КАЗАН – Россиянең Яңа ел башкаласы» проекты кысаларында Бөек Устюгтан килгән Кыш бабай Казан Кремле белән танышты. Анда ул балалар белән бергә «Казан – Россиянең Яңа ел башкаласы» дип аталган картинаны куюда катнашты. Әлеге панноны бәйрәмгә килгән балалар ясады, ә Кыш бабай аларга ярдәм итте. Бәйрәмнәрдән соң картинаны «Казан Кремле» музей-тыюлыгына тапшырачаклар. Кыш бабай балаларның «Апрель» тернәкләндерү үзәгендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге инвалид балалар өчен «Здравушка» социаль-тернәкләндерү үзәгендә дә булды.

### Төкле аягың белән, Эвелина

КАЗАНДА 2013 елның беренче көнендә туган сабыйга Эвелина исеме кушканнар. Баланың әнисе табиблар әйтүе буенча аны 3 гыйнварда гына табарга тиеш булган. Шуңа да Яңа елны әни кеше гаиләсе белән өендә бәйрәм иткән. Тик сәгать уклары төнге уникене суга башлауга, аны тулгак тота башлый һәм булачак әнине 4 нче бала тудыру йортына озаталар. Сабый 2 сәгать 50 минутта дөньяга килә. Бала тудыру йортының баш табиб урынбасары Нигина Нигъмәтуллина хәбәр иткәнчә, аларда Яңа ел төнендә рәттән тугыз кыз бала туган. Ә 1 гыйнварда барысы дөньяга 11 бала аваз салган.

### Поездга соңга кала күрмә

КАЗАН-КАНАШ-КАЗАН поездының 10 гыйнвардан расписаниесе үзгәрә. 6101 нче шәһәр яны поезды Казаннан 14 сәгать 56 минутта китәчәк. Юдинога 15 сәгать 20 минутка килеп, 1 минутка тукталыш ясый. Васильево станциясендә 15 сәгать 34 минуттан 15 сәгать 35 минутка кадәр була. Яшел Үзәндә 15 сәгать 46 минуттан 15 сәгать 47 минутка кадәр була. Канашка кичке сәгать алтынчы 20 минутка килә.

## ФОТОХӘБӘР

Шамил АБДЮШЕВ фотосы

### Чыршыгыз бигрәк матур

Аларны «Казан 2» вокзалында Кыш бабай һәм Кар кызы каршы алды. Соңыннан Кыш бабайлар белән Кар кызлары Казанда 1000 еллык паркындагы Төп чыршының утларын рәсми рәвештә кабыздылар. Төп Яңа ел чарасына йөзләгән казанлылар һәм башкала кунаклары килде. «Мин Казанда ничә тапкыр булсам да, шәһәрегезнең матурлыгына сокланып бетә алмыйм. Чыршы бүген бик матур», – диде Кыш бабай.


«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

## Президент төзелешләрне тикшерде

**ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда ике төзелеш объектында булды.**

Рөстәм Миңнехановны ТР Премьер-министры урынбасары Илдар Халиков, Казан мэры Илсур Метшин озатып йөрде. Президент Әмирхан проспектын һәм Максимов урамын тоташтыра торган яңа автомобиль юлы буенча йөреп килде. 1650 метрга сузылган юл КАПО һәм КМПО заводлары арасында салынган. Моннан тыш, Рөстәм Миңнехановка Максимов һәм Дементьев урамнары чатын реконструкцияләү проекты күрсәтелде. Яңа юл нәкъ менә шунда чыга. Монда әйләнмәле юллы чат булдыру көтелә. Авиатөзелеш районы транспорт инфраструктурасы үсеше планнарында Әмирхан проспектын һәм Максимов урамы магистрален М7 трассасы белән тоташтыра торган юл төзү дә бар. Р.Миңнеханов шулай ук Кадыш бистәсен автотранспорт агымыннан азат итү кирәклеген билгеләп үтте. Президент шулай ук реконструкция үткәрелә торган Качалов театры бинасын карады.

## Халыкның сәламәтлеген кайгыртып

**ТР район үзәк хастаханәләре баш табибларына 63 яңа ашыгыч медицина ярдәме автомобиле ачкычлары тапшырылды.**

Казанга ашыгыч медицина ярдәме автомобильләренең чираттагы партиясе кайтты. «Казан» халыкара ат-спорт комплексы территориясендә УАЗ автомобиле базасында 63 ашыгыч медицина ярдәме машинасы Татарстан карамагына күчте. Район үзәк хастаханәләренең баш табиблары машина ачкычларын ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов кулыннан кабул итеп алды.

«Яңа ел алдыннан бүген бик күңелле вакыйга. Халкыбыз сәламәтлеге нык булсын дип, республикада яңа хастаханәләр сафка баса, яңа ашыгыч медицина ярдәме машиналары кайтарыла. Минемчә, бүген башкарылучы эшләр сәламәтлек саклау тармагының заманча стандартларга җавап бирү максатын күзаллый. Фельдшер-акушерлык пунктлары, ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе төзелеше, булган оешмаларда төзекләндерү эшләрен үткәрү – медицина тармагында үрнәк булырлык гамәлләр», – дип билгеләде республика җитәкчесе. Президент ассызыклаганча, медицина өлкәсендә оперативлык хәлиткеч роль уйный.

## Татар теленә ихтыяҗ бар

**РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВКА «Ана теле» татар теленә дистанцион өйрәтү информацион-укыту проектын тәкъдим иттеләр.**

Исегезгә төшерик, «Ана теле» татар теленә өйрәтү on-line мәктәбе проекты ТР һәм EF Education First компаниясе белгечләре белән берлектә эшләнелә. Татарстан ягыннан проект эшенә югары квалификацияле филологлар, татар теле укытучылары җәлеп ителгән.

Президент хәбәр итүенчә, бүген дөньяда якынча 7 миллион татар яши, Россиядә соңгы халык санын алу буенча – 5,5 миллион кеше, аларның якынча 2 миллионы гына Татарстан территориясендә яши. Татар теленә, тел буларак, БДБ илләрендә, чит илдә ихтыяҗ бар, дистанцион өйрәнү күп ватандашларга туган телне үзләштерергә мөмкинлек бирәчәк. Р.Миңнеханов, кулланучылар программаның тест версиясенә якын арада керә алсыннар өчен, проект өстендә тагын да активрак эшләргә тәкъдим итте.

КАЗАН ХӘБӘРЛӘРЕ

# Артыгын түләттерсәләр, үзең тикшер

**Татарстан Премьер-министры Илдар Халиков телеэфирда торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләренә кагылышлы әңгәмә үткәрде.**

КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

– Гомумйорт ихтыяҗлары кискен проблемага әверелгәч, без түбәндәгеләрне эшләдек: күпфатирлы һәр йорт исәпкә куелды, – диде Премьер-министр Илдар Халиков. – Хәзер һәр йортның сәбәпләре аерым-аерым тикшерелә. Энергетикларның мөнәсәбәте гади – йортка кергәндә хисаплагыч куелган, аның буенча аена фәлән кадәр су тотылган, электр кулланылган һәм аны түләргә кирәк. Күршеләрегез урлаша – үзегез хәл итегез, дип, бөтен мәсьәләне йортларда яшәүчеләргә яки идарәче компанияләргә генә аударып калдырып булмый.

Премьер-министр шул ук вакытта гражданнарны да активрак һәм таләпчәнрәк булырга чакырды. Гомумйорт ихтыяҗлары (ОДН) 20 проценттан да югарырак исәпләнелгән очракларда йорт комитетын җыярга кирәклеген әйтте ул. «Йортка керүче хисаплагычны ышанычлы белдерелгән кеше, кирәк икән, ике, өч кеше тикшерсен. Йортларда яшәүче намуслылар урлашучы күршесе өчен дә түләү башкарырга тиеш түгел, моны булдырмау өчен, барысын да эшләргә кирәк», – диде Премьер-министр.

Йорттагы торбадан су агу яки коммуналь челтәрләргә рөхсәтсез ялгану очраклары ачыкланса, болар турында кичекмәстән хәбәр итү зарурлыгы искәртелде. Илдар Халиков: «Татарстан Президенты, республикада ОДН 20 проценттан да күбрәк итеп билгеләнгән күпфатирлы йортлар булмаска тиеш, дигән йөкләмә куйды. Кызганыч, әлегә андый йортлар берничә мең», – диде.

# Җылылык өчен субсидияләрне быел да түләячәкләр

**Узган елны торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә булган иң зур яңалыкларның берсе җылылыкка бәяләр күтәрелү һәм, аны бераз булса да йомшарту өчен, максатчан субсидияләр кертелү булгандыр.**

КАЙГЫРТУ

**Чулпан НӘҖИПОВА**

Белүебезчә, әлеге яңалык Казан, Чаллы, Түбән Кама һәм Зәй шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә (Ютазы районы), Афанасово, Красно-Ключинское авыл җирлекләрендә (Түбән Кама районы) яшәүчеләргә һәм җылылыкны «Таттеплосбыт» ААҖдән алучыларга кагылды. Субсидияләр гаиләдә бер кешегә булган табыш 30 меңнән артып китмәгән кешеләргә каралган иде. Алар акчаларны алты ай дәвамында алачаклар. Ә бу вакыт үткәннән соң, керемнәр турындагы белешмәләрне социаль яклау учреждениеләренә яңадан күрсәтергә онытмаска кирәк. Яңадан кайчан барырга кирәк булачагы турында мәгълүмат исә счет-фактура артында да язылып килачәк.

Җылылык өчен субсидия түләүләре Казанда быел да, ягъни 2013 елда да дәвам итәчәк. Моның өчен шәһәр бюджетыннан 1 миллион 600 мең сум акча бүлеп бирелгән, дип хәбәр ителә шәһәр мэриясе сайтында.

Җылылык өчен субсидия алу өчен гаризаларны кабул итүнең соңгы вакыты декабрь ахыры булса да, социаль яклау бүлекләренә быел да мөрәҗәгать итәргә була. Әмма шунысы бар – бу вакытта инде алдагы айлар өчен акча түләнмәячәк.

### Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясенең 1/1-3 нче КАРАРЫ

*29 декабрь 2012 ел*

**Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе рәисен сайлау турында**

«Сайлау хокукларының төп гарантияләре һәм Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашуга хокукы турында»гы Федераль законының 28 нче маддәсе, 5 нче пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 17 нче маддәсе, 5 нче бүлеге, Казан шәһәр Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 7-3 нче карары белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» Муниципаль казна учреждениесе турындагы кагыйдәләрнең 4.2. нче пунктына туры китереп, хисап комиссиясенең 2012 елның 29 декабрендәге 2 нче номерлы беркетмәсе нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе **карар кылды:**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе рәисе итеп Фәрит Каюм улы Гәрәевне сайларга.

**Комиссия рәисе Ф.К.ГӘРӘЕВ**
**Комиссия секретаре Н.Н.ПАВЛОВА**

### Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясенең 1/2-3 нче КАРАРЫ

*29 декабрь 2012 ел*

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе рәисенең урынбасарын сайлау турында**

«Сайлау хокукларының төп гарантияләре һәм Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашуга хокукы турында»гы Федераль законының 28 нче маддәсе, 8 нче пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 17 нче маддәсе, 10 нчы бүлеге, Казан шәһәр Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 7-3 нче карары белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» Муниципаль казна учреждениесе турындагы кагыйдәләрнең 4.2. нче пунктына туры китереп, хисап комиссиясенең 2012 елның 29 декабрендәге 3 нче номерлы беркетмәсе нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе **карар кылды:**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе рәисе урынбасары итеп Виктор Иосифович Яковлевны сайларга.

**Комиссия рәисе Ф.К.ГӘРӘЕВ**
**Комиссия секретаре Н.Н.ПАВЛОВА**

### Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясенең 1/3-3 нче КАРАРЫ

*29 декабрь 2012 ел*

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе секретарен сайлау турында**

«Сайлау хокукларының төп гарантияләре һәм Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашуга хокукы турында»гы Федераль законының 28 нче маддәсе, 8 нче пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 17 нче маддәсе, 10 нчы бүлеге, Казан шәһәр Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 7-3 нче карары белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» Муниципаль казна учреждениесе турындагы кагыйдәләрнең 4.2. нче пунктына туры китереп, хисап комиссиясенең 2012 елның 29 декабрендәге 4 нче номерлы беркетмәсе нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе **карар кылды:**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Сайлау комиссиясе секретаре итеп Наталия Николаевна Павлованы сайларга.

**Комиссия рәисе Ф.К.ГӘРӘЕВ**
**Комиссия секретаре Н.Н.ПАВЛОВА**

ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР

# Фән юлындагы тормыш

**Фәнни җәмәгатьчелек 2013 елның 1 гыйнварында тарих фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты урта гасырлар тарихы бүлеге җитәкчесе Илдус Котдус улы Заһидуллинның 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Илдус Котдус улы 1990 елларның авыр-болгавыр заманнарында да үзе юнәлеш алган фән юлыннан тайпылмыйча барган чын галим дип әйтергә тулы хокукыбыз бар. Күп кенә башка галимнәрдән аермалы буларак, ул фәнгә ниндидер әйләнгеч юллар белән килмичә, хезмәт юлын гыйлем эстәүдән, тарихның тирән катламнарын өйрәнүдән башлады дисәк тә була.**

Илшат **ФӘЙЗРАХМАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты

1985 елда Казан дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлаган Янгул егетен ул вакытта кабул ителгән билгеләнеш (распределение) буенча үз туган якларына – Балтач районының Түнтәр урта мәктәбенә тарих укытучысы итеп җибәрәләр. Әлеге мәктәптә укыту барышында ук инде аның һәм бергә эшләгән хәләл җефете Дания ханымның авылда гына калмыйча, фән өлкәсендә югары үрләргә ирешерлек чын татар интеллигенциясе вәкилләре булулары күренә. 1989 елда Илдус Котдус улы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлегенә аспирантурага килә, фәнни хезмәткәр вазифаларын башкара. 1992 елда «XIX гасырның икенче яртысында (60-90 нчы еллар) Казан губернасында татар крестьяннары» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. 1980 еллар ахыры-1990 еллар башында Татар милли университетын булдыру мәсьәләсе килеп чыккач, аның нигезен тәшкил итәргә тиешле Татар дәүләт колледжын (соңрак Татар дәүләт гуманитар институты) ачу һәм укыту процессын оештыру эше дә бу уку йортының директоры (соңрак ректоры) итеп билгеләнгән Илдус Котдус улына йөкләнелә. Административ эшләр күп вакытны ала, билгеле. Шуңа Илдус Котдус улы фәнни юнәлешен дәвам итү максатыннан да 1998 елда ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты урта гасырлар тарихы бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнә. Шушы чордан ул күптөрле фәнни-оештыру эшләренә керешә. Институтта эшләнелүче җиде томлы академик «Иң борынгы заманнан алып татар тарихы» китабының 1, 2 һәм 6 нчы томнарын әзерләүдә актив катнаша. Бүлек аның җитәкчелегендә ел саен күпсанлы конференцияләр үткәрә һәм аларның материалларын бастыруга әзерли.

Бүлектәге эш белән параллель рәвештә, Илдус Котдус улы фәнни эшчәнлеген дә киң күләмдә алып бара. Аның төп фәнни-тикшеренү темалары – Россия империясендә ислам институтлары, хөкүмәтнең татарларга һәм Идел-Урал төбәгендә яшәүче башка халыкларга карата сәясәте, Урта Идел буенда авыл хуҗалыгы, крестьяннар хәрәкәте, Казан тарихы һ.б.

2006 елда Илдус Котдус улы «XVIII гасыр уртасы-XX гасыр башында Россиянең Европа өлешендә һәм Себердә ислам диненең торышы» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый.

Күпсанлы мәкаләләреннән тыш, аның берничә монографиясе дә басылып чыкты: «1897 елгы перепись һәм Казан губернасы татарлары» (Казан, 2000), «Россия империясендә ислам институтлары: Санкт-Петербургта мөселман общинасы: XVIII-XX гасыр башы» (Казан, 2003), «Россия империясе оешмаларында мөселман богослужениесе» (Казан, 2006), «Түбән Новгород ярминкә мәчете» (Түбән Новгород, 2006).

Илдус Котдус улы шулай ук «Чын мирас» һәм «Научный Татарстан» журналларының редакция советларына да керә.

Башка яхшы сыйфатлары арасында, Илдус Котдус улының кешелеклелеген дә әйтеп үтәргә кирәк. Кайчан гына янына килмә, ул сине тыңларга әзер: үзенең акыллы, төпле киңәшләре белән ярдәм итә, кем белән генә булмасын, аның белән яхшы мөгамәлә саклый, тигез күреп сөйләшә, шуңа күрә зур хөрмәткә ия дә инде.

Без аның фәнни-оештыру эшләрендә яңа зур уңышларга ирешүен теләп калабыз.

## Сүз әйтер хәл юк кешегә...

Эльвира **МОЗАФФАРОВА**

Әллә заманасы үзгәрде, әллә кешеләре... Аңламассың. Күршем балалар бакчасыннан кайтып баргандә бер ир-атка шелтә ясый. Сәбәбе – тегесе пакет тулы чүп-чарын аның күз алдында йорт каршындагы эскәмия янында калдыра. Ир исә сүгенергә, әшәке сүзләр әйтеп кычкырырга тотына, кирпеч тотып, танышыма үтерәм дип тә яный. Соңыннан хатынын, баласын машинага утыртып кузгалганда «дошманын» бәрдерергә уйлый. Ярый танышым читкә тайпылып өлгергән. Ул да, тыныч кала алмыйча, тизлек алырга өлгермәгән машинаны куып тота. Ялгыш кагылганмы, машинаның ишеге ачылып китә. Тагын да котырынган ир-ат, кабинасыннан чыгып, танышымның җилкәсенә китереп суга. Әле бүген дә авыртуы бетми, ди. Кыскасы, хәзер күршеләремнең эше белән полиция шөгыльләнә. Бер сүз әйтер хәл юк шул кешегә...

## Хәбәр сал, дустым!

Исәнмесез, кадерле редакция! Сезгә хат язучы күрше Башкортстаннан хезмәт ветераны – пенсионер Тимерьян Салих улы Хабирьялов. Мин Сезнең редакция әзерләгән «Атна вакыйгалары» газетасын бик яратып укыйм, көтеп алам. Рәхмәт Сезгә. Минем сезгә бик зур үтенечем бар. Кукмарадан Фәрит Нәзиб улы Зарипов дигән кешене эзләп табасым килә. Без аның белән 1970-1978 елларда Тын океан флотында бер корабльдә хезмәт иттек. Башта сроклы хезмәт, ә аннан мичман булып. Аның Гүзәл исемле тормыш иптәше дә шул якларда иде. Минем кәләшем Альмира исемле иде. Без, гаиләләр белән дуслашып, кунакка йөрештек, ерак җирләрдә булсак та, татарлар икәнебезне онытмадык. Мин үзем гармунда өздереп тартча уйный, ә дустымның кәләше Гүзәл бик матур җырлый иде.

**Редакциядән:** Фәрит абый! Безнең газетаны укыйсыздыр дип өметләнәбез. Дустыгызның адресы редакциядә.

**Билгеле булганча, элек тә, хәзер дә армия хезмәтенә барырга тиешле егетләрне берничә ел алдан барлап, медицина тикшерүе үткәрәләр. Шулай безнең Кузнечиха районының (хәзер Әлки) Тогәлбай авылында яшәүче 1936 елда туган 26 яшүсмерне дә 1954 елның февраль аенда тикшерә башладылар.**

## Без никрут чакларда

Сөләйман **ШАКИРОВ**

Алтышар малайны Кузнечиха хәрби комиссариатына чакырып кына торалар. Бер чакыруда мин дә эләктем. «Кызылармеец» колхозы бригадиры Гәрәев Нургали абый безгә: «Менә, малайлар, сезгә алтыгызга бер ат. Утыра-төшә барырсыз», – дип, үрәчәле чанага салам җәеп, җигелгән ат бирде. Иртән сәгать 8дә атлар йорты янына җыелып беттек. Баштагы өч никрутыбыз – Сәйдәш, Хәсән, Садыйк бераз ачы бал эчеп кәефләнгәннәр, сумкаларында тагын бар әле. Калган өчебез – Мансур, Вәгыйз һәм мин андый әче әйбер белән мавыкмыйбыз, чөнки без – инвалидлар. Баштагы кәефләнгән өч никрут безгә карап үзара чыш-пыш килделәр дә: «Малайлар, без сезнең белән бармыйбыз. Үзегезгә аерым ат сорагыз», – дип, чанага утырдылар да, герман көенә җырлап, атны чаптырып китеп бардылар. Инде нишләргә? 10 чакрым ара кышын инвалидлар җәяү бара алмый бит. Бармый калырга да ярамый. Ул чакта бу эштә тәртип бик коры иде. Колхоз идарәсенә төшеп, хәлне аңлаттым. Нургали абый да шунда иде. Ул: «Ах, мәлгуньнәр икән. Кайтсыннар әле, күрсәтермен мин аларга герман көйләрен», – диде дә безгә үзе йөри торган атны бирде. Аның аты бик елдам, салам җәелгән артлы чанага утырып, бер сәгатьтә барып җиттек. Хәрби комиссариат йортына керсәк, алдан киткән өч никрут, сүгенешеп, тәкеренә-тәкеренә, комиссариат йортындагы бәдрәфне чистартып яталар. Килеп җиткәнче үк шактый кәефләнгән егетләргә хәрби комиссар армиягә барганчы ук чиратсыз наряд биргән икән, эшли-эшли айнып, кичен генә кайттылар. Безне, чиратсыз бер сәгатьтә карап, «ак билет» биреп кайтарып җибәрделәр. Ике ел төрле хастаханәләрдә дәвалангач, шөкер, савыктым. Аннан «ак билет»ымны алып, тыныч чакта хезмәткә ярамый, сугыш вакытында ярый, дип язып, кызыл тышлы хәрби билет бирделәр. Армиягә бик барасым килгән иде югыйсә.

## Кыш бабайда кунакта

Рәшидә **ХӘЙРЕТДИНОВА,**
Казан

Чатнама салкын булуга карамастан, узган елда Арчага юл тоттык. Барып чәйләр эчеп, хәлләр белешкәч, сүз иярә сүз чыгып, быел Казанның төп Яңа ел шәһәре буласын һәм Кыш бабайларның Кырлайда җыеласын әйтеп куйдым шунда. Кияү озак уйлап тормаган, Кырлай музеена шалтыратып та алган. Иртүк торып, 3 яшьлек оныкны да алып, Кырлайга юнәлдек.

Музей безне, сихри пароход кебек, яп-якты утлар белән каршы алды. Беренче катның матурлыгы һәм «Ягымлы Шүрәле» бәйгесенә килгән балалар иҗаты – кул эшләре белән танышып йөргәндә, Ульяновскидан (үзләре шулай диде) сәяхәтчеләр төркеме килеп төште. Безне ягымлы гына каршы алган Сөмбел Мөдәрис кызы үзе экскурсовод икән, шул төркемгә кушылып, сәяхәтебез башланды. Безне Кушлавыч, Өчиле һәм Кырлай авыллары буйлап йөртеп, кечкенә Габдулланың авыр язмышы, ул вакыттагы авыл тормышы белән таныштырды ул. Мәктәптә эшләгән вакытта бу музейда берничә тапкыр булсам да, күздән яшьләр чыкты. Ә Сөмбелнең Тукай иҗатын яратып, Тукаебыз белән горурланып шигырьләрен татарча да, русча да бик нәзакәтле итеп сөйләве йөрәкләргә барып җитте. Ульяновски кунаклары да, без дә сәяхәттән бик канәгать булып, зур рәхмәтләр әйтеп, Кыш бабай бүлмәсенә – икенче катка күтәрелдек. Мондагы матурлыкны язып кына бетерерлек түгел... Түр башында өрфия чыбылдык белән уратып алынган Кыш бабай караваты, өстәл өстендә зур самавыр, килгән кунакларның теләкләрен язып салу өчен зур-зур тәпәннәр, күз явын алырлык чыршы, шүрәлеләр... Без бормалы баскычлар буйлап аска төшкәндә, беренче каттагы бүлмәдә милли киемдәге егет-кызлар гармун һәм башка уен коралларында уйный башлаганнар иде инде.

## Милләтебез киләчәге һәркемне уйландыра, ләкин...

Мәүлидә **МИНГАЛЕЕВА**

Фәнил Гыйләҗевнең «Еламаган балага имезлек каптырмыйлар...» («ШК», 4.12.2012 № 138(5167) дигән мәкаләсен укыгач, язарга булдым әле. Иң элек Фәнил энекәшне журналистларның республикакүләм бәйгесендә беренче урын алуы белән тәбрик итәм. Ярый әле безнең милләт кайгыларын кайгыртып, төптән дәлилләр китереп язучы егетләребез бар!

Минемчә, милләтебез киләчәген кайгыртып, телебезне дәүләт теле итеп калдыруны күтәреп урамга чыгар алдыннан иҗтимагый оешмаларны берберсе белән таныштырырга, алай гына булмаса, «лидер»га халык белән сөйләшергә кирәк. Татар иҗтимагый үзәге үзенең эше, планнары турында халыкка бернинди дә мәгълүмат җиткерми. Митингларга карата кискен чаралар куллану турындагы карарлар болай да халыкны куркыта. Халык ЖКХ хакы кыйнавыннан да нишләргә белми инде... Дөрес, башка структуралар да үз өлешен кертергә тиештер. Фәндәс Сафиуллин, минемчә, үз тирәсендә телебезне дәүләт теле итеп калдыруда вакытын да, көчен дә кызганмый торган кешеләрне туплый алыр. Дипломатия, җыелыш карарлары, үз тирәңә күп кеше җыйганнан соң урамга чыгуның да нәтиҗәсе булыр.

Телебез турында фикерләрен белү өчен, мин бик күп клуб җитәкчеләре белән әңгәмә корып карадым, берсенең дә андый четерекле нәрсәләр белән баш ватасы килми. Күңел ачу, баш катырмау теләге көчле халыкта. Аркадий Крупняковның (Мари Эл китап нәшрияты – Йошкар-Ола, 1970) «Акпарс маршы» дигән китабында (299 нчы бит) Сөембикәнең Явыз Иван патша янына китәр алдыннан әйткән сүзләре китерелә: «Казан күп кешеле һәм көчле таркаулык ашап бетерә аны». Хәзер дә актуаль ул әйбер.

# Зур концерт залы

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

ЯҢА КАЗАН

Татарстан Хөкүмәте карары нигезендә, 1996 елда Дәүләт Зур концерт залы барлыкка китерелде. 2000 елда аңа композитор Салих Сәйдәшев исеме бирелде.

Баштарак бу урында Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залы урнашкан иде. Бина 1967 елда архитектор М.Агишев проекты буенча төзелгән. 1994 елда конструктор В.Абрамов, архитекторлар В.Логинов, Е.Прокофьев сызымнарына таянып, бинага реконструкция үткәрелде. Шәрык һәм Көнбатыш сәнгать үрнәкләрен кулланып төзекләндерелгән дивар гаҗәеп матур рәвеш алды. Залның акустика сыйфатлары камилләштерелде. Плафон татар милли орнаментлары кулланып бизәлгән. Нәкыш үрнәкләре борынгы Болгар шәһәрендәге Кара палатадан карап ясалган. Тамаша залындагы зур орган Европада иң яхшы музыка коралларыннан санала. Ул 1997 елда Нидерландтан «Flentrop» фирмасыннан кайтартылды. Шунысы да үзенчәлекле – залдагы акустиканы төрле музыкаль чыгышларга көйләп була. Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залы Казанның музыка тормышының әйдәүче үзәгенә әверелде. Биредә халыкара дәрәҗәдәге коллективлар чыгыш ясый, танылган дирижерларның һәм опера йолдызларының концертлары уза, фестивальләр үткәрелә.

# Тормыш ул — КӨРӘШ

**Көрәшче дигәч иң беренче булып, нык гәүдәле, карашы белән аюны да ега торган баһадирларны күз алдыма китерә идем. Язмамның герое белән танышкач, хаксыз булуымны аңладым. Егетләргә хас булмаган озын кара керфекләр, ачык йөз, матур елмаю... Бер карасаң, бу егет чебенне дә үпкәләтә алмый кебек. Ләкин беренче караш ялгыш фикерләр тудыра, диләр. Айназ Якупов – район, республика һәм Россия күләмендә спорт дөньясында шактый үрләр яулаган көрәшче. Әллә көндәшләрен сихерле елмаюы белән җиңә инде ул?**

ЯШЬТӘШ

**Алисә САБИРОВА**

## Беренче адымнар...

**– Айназ, спорт белән шөгыльләнеп китү тарихың белән таныштырсаң иде?**

– Дөресен генә әйткәндә, спортны кечкенәдән яратмадым. Физкультура дәресләре минем өчен бер зур сынау иде. Нигәдер күңелем тартмады аңа. Өченче сыйныфта миңа икенче мәктәпкә күчәргә туры килде. Менә шунда үзгәрде дә инде спортка карашым. Монда укыту системасы да башка, укытучы да күпкә катырак, таләпчәнрәк иде. Әле дә бер нормативны бирер өчен ничек азапланганымны хәтерлим. Үземнең башкалардан шактый калышканымны күрепме, 7-8 нче сыйныфларда дәресләрдән соң мәктәп тренажерына йөри башладым.

**– Ә көрәшкә мәхәббәт чын-чынлап кайчан кабынды соң?**

– Элек Сабан туйларында данлыклы көрәш батырларына карап соклана идем. Аларны бөтенесе белә, хөрмәт итә, ярата. Минем дә алар урынында буласым килде. Көрәш белән шөгыльләнеп китүемнең тагын бер сәбәбе – 2008 елда Пекинда үткәрелгән Олимпия уеннары. Уеннарны телевизордан күзәткәндә беренче тапкыр ирекле көрәшнең нәрсә икәнен күрдем. Аларның хәрәкәтләренә, үз-үзләрен тотышына таң калдым. Менә шунда гашыйк булдым да инде көрәшкә. Мәктәптә ирекле көрәшне өйрәнергә теләүчеләрне җыябыз дигән игълан ишеткәч тә туп-туры шул секциягә язылырга чаптым.

Спорт тормышы шактый катлаулы икәненә шунда гына төшенә Айназ. Көнне төнгә ялгап тренировкалар үткәрү, нормативлар бирү... Спортзал һавасын сулап шулай берничә ел үтә дә китә. Баштарак көрәш серләре авыр бирелә. Ләкин табигате белән үзсүзле егетнең тиз генә бирешәсе килми. Абыйсына ияреп, инде көрәшче буларак шактый җитлеккән, тәҗрибә җыйган көрәшчеләр белән бергә шөгыльләнә башлый. Тора-бара Сабан туйларында, төрле ярышларда катнашып, лаеклы урыннарга ирешә ул.

## Уеннан башланган тормыш

**– Айназ, иң беренче көрәшеңне хәтерлисеңме?**

– Дөресен генә әйткәндә, беренче көрәштә катнашуым дәрескә бармас өчен генә килеп чыкты. *(Көлә.)* Әле көрәшнең нәрсә икәнен дә аңламый идем. Мәйданга чыгар алдыннан буыннарны да җылытмадым. Җиңелдем инде, әлбәттә. Минем өчен иң оят булган чакларның берсе ул. Мин тумышым белән кире кеше. Шул вакытта үз-үземә шушы турнирны җиңәргә дигән сүз бирдем. Һәм җиңдем дә.

**– Син җиңелә беләсеңме?**

– Көрәштә җиңүләр дә, җиңелүләр дә була. Җиңелсәм дә, матур җиңелергә тырышам. Гадел көрәш белән.

**– Көрәш буенча алган белемнәреңне тормышта кулланырга туры килгән очраклар бармы?**

– Көрәш белән шөгыльләнә башлаганнан бирле урамда азрак сугыша башладым. Барлык энергия, канны кыздыручы адреналин спорт залында кала. Көрәш хисләрне контрольдә тотарга өйрәтә. Үз-үзеңне тыя башлыйсың.

**– Сабан туйларында катнашуга ничек карыйсың?**

– Барлык көрәшчеләр дә, башка төрле ярышларга караганда, Сабан туе ярышларын өстенрәк куя, минемчә. Анда синең бөтен туганнарың, әти-әниләрең, дусларың, алар алдында оятка каласы, җиңеләсе килми бит.

**– Җәрәхәтләр алу очраклары булгаладымы?**

– Ансыз булмый инде. Менә хәзер дә сул аягымның буыннары тартылган. Ләкин, җәрәхәт алам, дип, спорттан куркырга кирәкми. Һәрбер чыккан кул һәм аяк, кара янган, шешкән урыннар холкыңны гына ныгыта. Мәйданда авырлыкларга түзәргә өйрәнсәң, тормышта да түзәсең инде.

**– Синең өчен көрәш нәрсә ул?**

– Хәзерге вакытта ул минем бөтен тормышым. Спортка күбрәк вакыт сарыф итәсем килә. Буш вакытымда йөгерәм. Берничә тренажеркага йөрим.

**– Спорт – тормышым, дисең, ә иң якын дустың белән бер мәйданга чыксаң, нишләр идең?**

– Беләсеңме, көрәшчеләр арасында шундый сүз бар: «Мәйданда – көндәш, мәйдан артында – дус!» Бу – безнең төп кагыйдәбез. Тормышта нинди генә дуслар булсак та, без – көрәшчеләр. Көрәш мәйданында булган шунда кала. Ярышлардан соң син мине алып салдың, дип үпкә белдереп йөрмибез.

**– Ирекле көрәш татар-башкорт көрәшеннән нәрсә белән аерыла?**

– Ирекле көрәш татар-башкорт көрәшеннән матуррак, кызыклырак. Тикмәгә генә ул ирекле дип аталмаган инде. Монда татар-башкорт көрәшендә булмаган кагыйдәләр, алымнар бар. Форма бүтән, кулда сөлге юк, аякларны да кулланырга ярый.

**– Көрәштә кумирларың бармы?**

– Алай бирелеп бер кешене дә кумир итеп куймыйм. Ләкин кайбер көрәшчеләрнең техникалары, көрәш вакытында үз-үзләрен тотышлары белән кызыксынам.

**– Киләчәккә планнар нинди?**

– Көрәш белән шөгыльләнүемне дәвам итәсем килә. Туып үскән төбәгемә кайтып, анда ирекле көрәш секциясен ачу теләге дә бар.

Кыскача белешмә:

*Тулы иселе –Айназ Алмаз улы Якупов*
*Туган елы – 22 март, 1994*
*Белеме – КФУ, тарих бүлеге*
*Тормыш девизы: тормыш ул – көрәш*

КИҢӘШ-ТАБЫШ

## Кукуруз ашаган чибәр булыр

Кышкы суык көннәрдә бик азлар гына куе чәчләре, сәламәт бит тәсе һәм сөйкемле елмаю белән шаккатыра. Әмма дөрес итеп сайланган меню әлеге ситуацияне төзәтергә дә әзер.

### Чәчләр өчен

Баш киемнәре һәм үзәк җылыту батареялары чәчне корыта. Шуңа да сезнең өстәлегездә түбәндәгеләр булырга тиеш:

√ Бавыр. Аңарда тимер күп. Ул җитешмәгән очракта, чәч очлары сынучан һәм коры була. Тик бавырны озак кыздырырга кирәкми – югыйсә ул тәмен генә түгел, файдалы үзлекләрен дә югалта.

√ Чикләвекләр. Аларда чәчләрнең сыгылмалылыгын тәэмин итә торган бакыр күп. Әмма фигураларын саклаучыларга чикләвекне көненә 30 граммнан да артык ашарга ярамый.

### Тән тиресе өчен

Салкын җил һәм фатирлардагы коры һава аркасында тән тиресе кубалаклана башлый. Моңардан нәрсә ярдәм итә ала?

√ Балык. Балыкның майлы сортларында алыштыргысыз омега-3 майлы кислотасы бар. Алар тиредәге дымны тоткарлый. Тик җылытканда майлы кислоталар җимерелә, шуңа да тозлы сельдь балыгын ашарга кирәк.

√ Карабодай. Табиблар аны рутинга бай булганы өчен өстен куя. Ул вак кан тамырлары тышчаларын тыгыз итә. Шуңа да карабодай боткасы суыкта борыны кызара торган кешеләр өчен файдалы. Карабодай кан әйләнешен дә яхшырта.

### Тешләр өчен

√ Алма. Теш табиблары ул теш эмаленең төсен яхшырта, кариеска китерүче микробларга каршы көрәшергә булыша дип ышандыра.

√ Кукуруз. Латин Америкасы кешеләренең нык һәм сәламәт тешләре – кукурузны еш куллану нәтиҗәсе.

**Газетаның киләсе саны 10 гыйнварда чыга**

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Без бергә булганда гына көчле!**

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: «ТАТМЕДИА» ААҖ
www.shahrikazan.com
Реклама хезмәте телефоны: (843) 562-50-12

Шәһри КАЗАН

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры – баш мөхәррир Мансур Газизҗан улы МОРТАЗИН

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: 420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Http://shahrikazan.com
E-Mail: shahri-kazan@tatmedia.com
ТЕЛЕФОННАР: 562-50-12 – кабул итү бүлмәсе, 562-50-07 (факс), 562-63-90 – бухгалтерия, 562-50-03 – хатлар бүлеге.
НӘШРИЯТ: «ТАТМЕДИА» ААҖ 420097, Казан, Академия ур., 2

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды.

БАСМАХАНӘ: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы
График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НАЦИОНАЛЬНАЯ ТИРАЖНАЯ СЛУЖБА
Тираж сертификацияләнгән.
Тираж – 3404 данә

Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.
Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
© Газетада басылган язмаларны файдаланганда, шулай ук өзекләр китергәндә «ШК»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.
Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга
Заказ 29461
ИНДЕКСЛАР: 54126 (3 тапкыр чыга), 16076 (пәнҗешәмбе саны) 54207 (оешмалар өчен)
Сатудагы бәясе ирекле
12+